КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 12 ноябрь г.Казань № 1020

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программалары буенча белем алучылар киеменә карата таләпләр раслау турында» 2013 ел, 29 июль, 527 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программалары буенча белем алучылар киеменә карата таләпләр раслау турында» 2013 ел, 29 июль, 527 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында белем алучылар киеменә карата бертип таләпләрне раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында белем бирүне дөньяви характерда тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында белем алучылар киеменә карата бертип таләпләрне (алга таба – Бертип таләпләр) расларга.»;

2 нче пунктта «таләпләр» сүзен «бертип таләпләр» сүзләренә алыштырырга;

3 нче пунктта «таләпләр» сүзен «бертип таләпләр» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында белем алучылар киеменә карата бертип таләпләрдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында белем алучылар киеменә карата бертип таләпләр»;

1 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында белем алучылар киеменә карата бертип таләпләр (алга таба шул ук эзлеклелектә – укучылар киеме, белем бирү оешмалары) түбәндәге максатларда кертелә:»;

2 нче пунктның беренче абзацында «башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү бирүче» һәм «(алга таба – мәгариф оешмалары)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 нче пунктның «б» пунктчасында татар текстында «югары булмаска тиеш)» сүзләреннән соң «; илнең салкын вакытында – нейтраль яки ачык булмаган төсләрдәге джемперны, свитерны, пуловерны (шакмаклы яки буйлы тукыманы файдаланырга мөмкин).»;

13 нче пунктта «мәгариф оешмасының дәүләт-иҗтимагый идарәсе – Белем бирү оешмасы советы тарафыннан» сүзләрен «мәгариф оешмасының локаль норматив акты белән» сүзләренә алыштырырга;

14 нче пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин